Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советының алтынчы утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советы
карары

29 декабрь, 2020 ел № 42

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында Казан – Шәмәрдән автомобиль юлының 21+977 – 22+777 км участогын реконструкцияләү» объекты буенча территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты составында территорияне планлаштыру документларын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә, «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында Казан – Шәмәрдән автомобиль юлының 21+977 – 22+777 км участогын реконструкцияләү» объекты буенча 2020 елның 21 декабрендәге гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм территорияне планлаштыру проекты составында территорияне планлаштыру документациясен һәм территорияне ызанлау проектын карау буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында Казан – Шәмәрдән автомобиль юлының 21+977 – 22+777 км участогын реконструкцияләү» объекты буенча территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты составындагы территорияне планлаштыру документларын электрон чыганакта, кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов